РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘР
СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның 14 апреле № 17

**«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Түбән Кама шәһәр Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның аерым статьяларына кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр, 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасы Конституциясенең аерым статьяларына кертелгән үзгәрешләр белән бәйле рәвештә, шулай ук «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Түбән Кама шәһәр Советы карары проектын хупларга һәм гавами тыңлауларда фикер алышуга чыгарырга (1 нче кушымта).
2. «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Түбән Кама шәһәр Советы карары проекты буенча гавами тыңлауларны 2023 елның 02 маенда 15.00 сәгатьтә Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр проспекты, 12 нче йорт адресы буенча Советлар йортының зур залында уздырырга.
3. «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Түбән Кама шәһәр Советы карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен һәм гражданнарның фикер алышуда катнашуын расларга (2 нче кушымта).
4. Түбән Кама шәһәре башкарма комитетына Түбән Кама шәһәр Советы оештыру бүлеге белән берлектә:

4.1. әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.e-nkama.ru) урнаштырырга;

4.2. әлеге карарны «Нижнекамская правда» газетасында бастырып чыгарырга;

4.3. Түбән Кама шәһәр Советының 2006 елның 13 октябрендәге 24 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә (матбугат басмасында - 2006 елның 10 ноябрендәге 220-221 (8572-8573) номерлы «Ленинская правда» газетасында бастырылган) ярашлы рәвештә, гавами

тыңлаулар үткәрүне, гавами тыңлауларда катнашу өчен гражданнардан һәм вазыйфаи затлардан килгән тәкъдимнәр һәм гаризалар кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры
вазыйфаларын башкаручы,
Мэр урынбасары
М.В. Камелина

Түбән Кама шәһәр Советының
2023 елның 14 апрелендәге
17 номерлы карарына
1 нче кушымта

ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘР СОВЕТЫ
КАРАРЫ ПРОЕКТЫ

№ __ ____________ 2023 ел

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьялары, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 94, 95, 96 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Түбән Кама шәһәр Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен караганнан соң, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2016 елның 14 апрелендәге 17 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.
3. Түбән Кама шәһәре Мэрына әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры Р.Х. Муллин

Түбән Кама шәһәр Советының 2023 елның
__ ___________________
номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. «Шәһәрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре» 6 статьясында:

а) 1 өлешендә:

- түбәндәге эчтәлектәге 22.1, 22.2 пунктлар белән тулыландырырга:

«22.1) шәһәр торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманчылык, алар составындагы участок урманчылыкларын булдыру, гамәлдән чыгару, аларның чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында карарлар кабул итү, шулай ук шәһәр торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларын эшләү һәм раслауны гамәлгә ашыру;

22.2) шәһәр торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманнарга карата урман төзелеше чараларын гамәлгә ашыру;»;

- 37 пунктында «, ясалма җир кишәрлеге булдыру турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион үткәрү» сүзләрен төшереп калдырырга.

б) 3 өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон һәм «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон таләпләренә туры китереп, Татарстан Республикасы законнары белән гамәлгә ашырыла.».

2. «Муниципаль сайлаулар»15 статьясында:

а) 6 өлешнең икенче абзацында «шәһәр сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алыштырырга;

б) 7 өлештә «һәм әлеге Устав белән» сүзләрен төшереп калдырырга.

3. «Шәһәр Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирү» 16 статьясында:

а) 5 өлештә «шәһәрнең сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алыштырырга;

б) 8 өлештә:

- беренче җөмләдә «шәһәр сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алыштырырга;

- икенче җөмләдә «сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алыштырырга;

в) 13 өлештә «шәһәр сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алыштырырга.

4. «Гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар» 22 статьясының 3.1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Түбән Кама шәһәре генераль планы проекты, шәһәрнең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне межалау проектлары, территорияне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында муниципаль хокукый актлар проектлары, рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турында муниципаль хокукый актлар проектлары, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү, җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын файдалануның рөхсәт ителгән бер төрен җирдән файдалану һәм төзелешнең расланган кагыйдәләре булмаганда мондый файдалануның икенче төренә үзгәртү мәсьәләләре буенча шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнарга ярашлы рәвештә гавами тыңлаулар яки иҗтимагый фикер алышулар үткәрелә.».

5. «Шәһәр Советы составы» 31 статьясының 6 өлешендә «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алыштырырга.

6. «Шәһәр Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи заты, муниципаль вазыйфаны биләүче башка зат статусы» 32 статьясында:

а) 3.1 өлешендә «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгын (Рәисен)» сүзләренә алыштырырга;

б) 3.2 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алыштырырга;

в) 3.3 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

б) 6 өлешнең 2 пунктында:

- «а» пунктчасында «муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алыштырырга;

- «б» пунктчасында:

«муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органнарына сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе» сүзләренә алыштырырга;

«Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алыштырырга.

7. «Шәһәр Советы компетенциясе» 35 статьясындагы 1 өлешнең 16 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

8. «Шәһәр Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату» 42 статьясында:

а) 1 өлешен түбәндәге эчтәлекле 11.1, 11.2 пунктлары белән тулыландырырга:

«11.1) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне үтәмәү;

11.2) муниципаль берәмлекнең барлык шәһәр Советы утырышларында алты ай рәттән җитди сәбәпләрсез депутатның булмавы;»;

б) 2 өлешнең икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алыштырырга.

9. «Шәһәр Мэры - шәһәрнең югары вазыйфаи заты» 43 статьясының 2 өлешендә «шәһәр Советы» сүзләреннән соң «үз составыннан» сүзләре белән тулыландырырга.

10. 44 статьяда «Шәһәр Мэрын сайлау тәртибе» 44 статьясындагы 1 өлешнең беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алыштырырга.

11. «Шәһәр Мэры вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату» 48 статьясында:

а) 1 өлешне түбәндәге эчтәлекле 3.1 пункт белән тулыландырырга:

«3.1) «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25 статьясындагы 13 пунктына ярашлы рәвештә вазыйфасыннан китү;

б) 6 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алыштырырга.

12. «Шәһәр башкарма комитеты вәкаләтләре» 51 статьясындагы 3 пунктында:

а) 3.10 пунктчасында «, ясалма җир кишәрлеге булдыру турында шартнамә төзү хокукына ачык аукцион үткәрү» сүзләрен төшереп калдырырга.

б) түбәндәге эчтәлекле 3.15, 3.16 пунктчалары белән тулыландырырга:

«3.15) шәһәр торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманчылык, алар составындагы участок урманчылыкларын булдыру, гамәлдән чыгару, аларның чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында карарлар кабул итү, шулай ук шәһәр торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманчылыкларның урман хуҗалыгы регламентларын эшләү һәм раслауны гамәлгә ашыру;

3.16) шәһәр торак пунктлары җирләрендә урнашкан урманнарга карата урман төзелеше буенча чараларны гамәлгә ашыру;».

13. «Шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе» 52 статьясында:

а) 8 өлешендә «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә)» сүзләренә алыштырырга;

б) 10 өлешендә «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгын (Рәисен)» сүзләренә алыштырырга;

в) 11 өлешендә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алыштырырга.

14. «Шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату» 56 статьясында:

а) 1 өлешне түбәндәге эчтәлекле 4.1 пункты белән тулыландырырга:

«4.1) «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25 статьясындагы 13 пунктына ярашлы рәвештә вазыйфасыннан китү;

б) 2 өлешнең 2 пунктында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алыштырырга;

в) 2.1 өлешендә «Татарстан Республикасы Президентын» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгын (Рәисен)» сүзләренә алыштырырга.

15. «Сайлау комиссиясе» VIII бүлеген үз көчен югалткан дип танырга.

16. «Шәһәр Советы депутаты, башка вазыйфаи затлар эшчәнлегенең социаль һәм башка гарантияләре» 65 статьясының 3 өлешендә:

а) «һәм шәһәр сайлау комиссиясен» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) «бу органнар» сүзләрен «бу орган» сүзләренә алыштырырга.

17. «Муниципаль хокукый актларны әзерләү» 74 статьясындагы 1 өлешендә «һәм сайлау комиссияләре тарафыннан» сүзләрен «комиссия тарафыннан» сүзләренә алыштырырга.

18. «Муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка чыгару) һәм үз көченә керү тәртибе» 78 статьясының 9 өлешендә:

а) беренче абзацны түбәндәге эчтәлекле сүзләр белән тулыландырырга:

«, һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (pravo.tatarstan.ru) җирле үзидарә органнары арасында төзелгән муниципаль хокукый актның яки килешүнең тулы текстын беренче тапкыр урнаштыру (бастырып чыгару);

б) икенча абзацның икенче җөмләсендә «муниципаль хокукый актның» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (pravo.tatarstan.ru) һәм\яки» сүзләре белән тулыландырырга.

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары

М.В. Камелина

Түбән Кама шәһәр Советының
2023 елның 14 апрелендәге
17 номерлы карарына
2 нче кушымта

## «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА» ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘР СОВЕТЫ КАРАРЫ ПРОЕКТЫНА ГРАЖДАННАР ТӘКЪДИМНӘРЕН ИСӘПКӘ АЛУ ТӘРТИБЕ

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проектына тәкъдимнәр Түбән Кама шәһәр Советына Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр проспекты, 12 (Советлар йорты бинасы), 206 нчы кабинет адресы буенча яки gorsovet.nk@tatar.ru электрон почта адресы буенча электрон рәвештә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге үрнәк буенча төзәтмәләр таблицасы рәвешендә кертелә:

| т\с | Пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмәне исәпкә алып, проект тексты | Төзәтмә авторы (Ф.И.А.ис., адрес, телефон, эш (уку) урыны |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

2. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларында катнашу өчен гаризалар Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр проспекты, 12 адресы буенча шәхсән яки почта аша (конвертта «Устав турында фикер алышу» яки «Гавами тыңлаулар» билгесе белән), шулай ук gorsovet.nk@tatar.ru электрон почта адресы буенча электрон рәвештә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бирелә.

Гаризалар эш көннәрендә 8 дән 17 сәгатькә кадәр гавами тыңлаулар датасына кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре Түбән Кама шәһәр Советының оештыру бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм Түбән Кама шәһәр Советының регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә карау өчен тапшырыла.

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары
М.В. Камелина